БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 01 2021 ел № 32

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү турында
тәкъдимнәр әзерләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясындагы 2 өлеше һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булып торуын һәм авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль район җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләүне башларга.
2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрен территориаль планлаштыруның шәһәр төзелеше документлары проектын әзерләү буенча комиссиягә (Балтач район башкарма комитетның 2009 елның 2 июлендәге 249 номерлы карары (2020 елның 21 гыйнварындагы 34 номерлы үзгәрешләр белән)) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең генераль планына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган тәртиптә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү буенча эш алып барырга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов